


Рузаевка шәһәрендә «Кvпмәдәни мирас шартларында мәктәп укучыларына белем һәм тәрбия бирv» III республика педагогик фәнни-гамәли конференциясе узды. Кадошкино урта мәктәбе педагоглары ел саен әлеге чарада актив катнаша.
Агымдагы уку елында да рәхәтләнеп катнашканнар. «Балаларга рухи - әхлакый һәм патриотик тәрбия бирvнен кvпмәдәни традицияләре» секциясендә тарих һәм жәмгыять белеме укытучысы Равил Харис улы Казанбаев «Йомышлы татарлар костюмынын эволюциясе» дигән доклад белән чыгыш ясаган.

Равил Харис улы Казанбаев белән якынрак таныштырасы килә. Аз сvзле, тыйнак, ярдәмчел, әдәпле... мондый кешеләр доньяда азайганнан-азая бара. Әлеге эпитетларнын дореслегенә инанырга урын бар. Тырышлыгы нәтижәсендә кvпкә ирешкән: топле белеме бар, яраткан профессиясе, укучылары һәм коллективы; бvләкләре байтак – болар барысы да Кадошкино урта мәктәбенен тарих укытучысы Равил Харис улы Казанбаев турында. Анын белән аралашырга кызыклы. Предметын ярата, видеофильмнар тошерә, моржевание белән шогыльләнә, заманында ватык пыяла остендә дә йоргән, гитарада уйный, vзе яшәгән авыл балаларына шугалак ясаша, бакчасында гөлләрнен ниндие генә vсми... Ә бит ул гади авыл малае, барысына да ихтыяр коче белән ирешкән. Кечкенә авыл малаенын, доньясы авыл белән генә чикләнми. Хыяллары тормышын кызыклырак иткән. Ул кvп нәрсә турында хыяллана, тормышта максат куя, максатына ирешә. Кочле кеше очен vз-vзенне жинvнен мәгънәсе шунда. Кvз алдына китерегез, vткән гасырнын 70-80 нче еллары. Равил Большие Поляны мәктәбе укучысы. Кvп нәрсәгә ойрәнәсе, кvп нәрсәне беләсе бар анын. Булачак

профессиясен сайлауда ана мактаулы тарихчы, озын-озак еллар мәктәпнен алыштыргысыз завучы Яхья Амин улы Мангутовнын дәресләре булыша. Ул педагог булып кына калмый, тарих белән кызыксынучы киләчәк буында тәрбияли. Дvрт дистә елга якын Равил Харис улы Казанбаев педагогика белеменә тырышып хезмәт итә: бvген Россия Федерациясе һәм Мордовия Мәгариф Министрлыкларынын Мактау Грамоталары белән бvләкләнгән укытучы.
Равил Харрис улы сәяхәт итә, сәфәрләр ярата. Һәм хыялланганча, һәрвакыт инбашында камера. Шулай итеп туган ягы турында тарихи мизгелләр калдыра. Ул vз авылына, кече ватанына тугры кала. Диплом белән бергә Рузаевка районына юллама ала һәм шунда биографиясенен берничә елын vткәрә. Әтисе Харис Абдрахман улы бакыйлыкка кvчкәч, әнисе Фәридә Абдулла кызы ялгызы калгач, улы Равил ана ярдәм итәргә туган йортына кайта. Ул кече ир-ат һәм әти-әнисе алдындагы бурычын тулысынча vти. Барлык игелек, жылылык, ярдәм һәм дога Фәридә Абдулла кызы белән Харис Абдрахман улы икәнен һәрвакыт хәтерли. Хәтта хәзер, алар янында булмаганда да.
Ул vз предметын программа кысаларыннан чыгып бирә: яшvсмер анында белемнен бар нечкәлекләрен туплый, анларга ойрәтә. Шул вакытта Ватан очен жаваплылык та, горурлык та, патриотлык та vсәчәк, ди педагог. Равил Харис улы гомуми тарихтан сон Ватан тарихын ойрәнә башлагач, укучыларнын эчтән vзгәрvләрен тәжрибәдән vк белә. Тарихи вакыйгаларны vзләренеке, туганнарныкы кебек кабул итәләр. Ойрәнәләр, укыйлар, кызыксыналар. Ө Ватан сугышы чорын рамкалар белән чикләп буламыни? Бу тема укытучынын vзенен дә яраткан темаларыннан берсе. Ул кvп вакытын архивларга һәм эзләнv эшләренә, якташларынын исемнәрен мәнгеләштерvгә багышлый. Һәм билгесез, онытылган нәрсәләрне таба алуына шат - белсеннәр, истә тотсыннар очен дәресләр багышлый. Тарих дәресләре чыннан да Хәтер вахтасына әйләнә. Равил Харис улы кече ватанынын чын патриоты һәм укучыларын да шулай тәрбияли.

Наилә НАСЫРОВА